ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.03.2020 № 128

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 337 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хөкүмәтнең «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны һәм бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кетү турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 337 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина дип, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле (1 нче кушымта) итеп тану турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән Нигезләмәгә 2нче кушымтада: атаманы "(күпфатирлы йортның)" сүзләре белән тулыландырырга; ачыклаучы юлдагы "бинаның урнашу урыны" сүзләреннән соң "(күпфатирлы йортның)" сүзләрен өстәргә;

“бинаны тикшерүне уздырды” сүзләрен “күпфатирлы йортның” сүзләре белән тулыландырырга;

“бинаны тикшерү турында әлеге актны төзеде” сүзләрен “күпфатирлы йорт” сүзләре белән тулыландырырга;

“торак урыны торышының кыскача тасвирламасы” сүзләрен “Төзелеш конструкцияләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

"г" пунктчасында "проект-эзләнү эшләре һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

51 пунктта "Комиссия" сүзен “тиешле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы" сүзләренә алмаштырырга";

45 пунктның "д" пунктчасында "проект-эзләнүле" сүзен "махсуслаштырылган" сүзенә алмаштырырга".

44 пунктның өченче абзацында "проект-тикшеренү оешмасы" сүзләрен “инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм биналар һәм корылмаларның, аларның төзелеш конструкцияләренең грунт торышын тикшерү буенча эшләрне башкаруга хокукы булган үзкөйләнешле оешма (алга таба махсуслаштырылган оешма) әгъзасы булган юридик зат" сүзләренә алмаштырырга".

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"34. Күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле төзелеш корылмаларының (конструкцияләрнең) яисә күпфатирлы йортның авария хәлендәге техник халәте, аларны күпфатирлы йортның тотрыклылыгын югалтуга китерергә мөмкин булган җимерелү мөмкинлеген һәм (яисә) авышканлыкны дәлилләүче зыян күргән җимерелүләр дип тану өчен нигез булып тора.

Әгәр күпфатирлы йорт авария хәлендә дип табылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип табылса, мондый күпфатирлы йортта урнашкан торак биналар яшәү өчен яраксыз дип санала."

32 пунктта "дистиламин" сүзен "диметиламин" сүзе белән алмаштырырга ".

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов